КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 июнь г.Казань № 457

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1013 нче; 2022 ел, 11 май, 428 нче; 2022 ел, 10 сентябрь, 976 нчы; 2023 ел, 20 апрель, 500 нче; 2023 ел, 8 июль, 805 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «грантлар» сүзен «грант» сүзенә алмаштырырга, татар текстында «финанслаша торган» сүзләре үзгәрешсез кала, «гаилә фермаларын үстерүгә» сүзләрен «гаилә фермасын үстерүгә» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «грантлар» сүзен «грант» сүзенә алмаштырырга, татар текстында «финанслаша торган» сүзләре үзгәрешсез кала;

алтынчы абзацта «грантлар» сүзен «грант» сүзенә алмаштырырга, татар текстында «финанслаша торган» сүзләре үзгәрешсез кала;

әлеге карар белән расланган Гаилә фермаларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грантлар бирү тәртибен, Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грантлар бирү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган хуҗалыкларны төзү һәм (яисә) үстерү проектларын гамәлгә ашыруга бәйле «Агростартап» грантларын бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибендә:

1.5 пунктның икенче абзацында «(алга таба – җитештерү проектлары)» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктта:

«в» пунктчасын  түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Тәртипнең 1.5 пунктындагы икенче абзацында каралган чыгымнар юнәлешләре өчен грант сорап мөрәҗәгать иткәндә:

төзегәндә, реконструкцияләгәндә – үз-үзен җайга сала торган оешмага керергә рөхсәте булган оешма тарафыннан эшләнгән эре күрсәткечләр яисә аналог объектлар буенча җыелма смета исәп-хисабы яисә, проект-смета документациясен теркәп, капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе яки, проект-смета документациясен теркәп, капиталь төзелеш объектын төзүнең (реконструкцияләүнең) смета бәясен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе (капиталь төзелешнең аерым торган, катлар саны ике каттан артмаган җитештерү объектлары өчен (аларның гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил итә));

капиталь ремонт ясаганда – үз-үзен җайга сала торган оешмага керергә рөхсәте булган оешма тарафыннан эшләнгән эре күрсәткечләр яисә аналог объектлар буенча җыелма смета исәп-хисабы яки, проект-смета документациясен теркәп, капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

җитештерү объектлары сатып алганда – грант акчасы исәбеннән сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслый торган документлар (түләүгә счетлар, сатып алу-сатуның һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүнең якынча шартнамәләре, бәйсез бәяләүче тарафыннан күчемсез мөлкәтне бәяләү актлары);»;

«и» пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«и) заявка бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көн алдан бирелгән җитештерү күчемсез мөлкәт объектларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә һәм Россия

Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, проектта катнашкан җитештерү күчемсез мөлкәт объектларына аренда шартнамәсе күчермәсе;»;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасы өстәргә:

«г) грантны җитештерү объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга кулланганда, яңа эшли башлаган кооператив түбәндәгеләргә бурычлы:

килешү төзелгән көннән алып 6 айдан да соңга калмыйча, дәүләт экспертизасы узган проект-смета документациясен эшләргә һәм тәкъдим итәргә;

төзелеш-монтаж эшләрен подряд ысулы белән башкарып чыгарга һәм эшләр башкару барышында үз-үзен җайга сала торган оешмага керергә рөхсәте булган оешма тарафыннан һәм, әлеге эшне башкаручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм реестрына кертелү шарты белән төзелеш контролен гамәлгә ашырырга.»;

5.5 пункттагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Т/с | Критерий исеме | Күрсәткечләр | Бәя баллда |
|---|---|---|---|
| 1. | Яңа эш башлаучы кооперативның милкендә һәм (яисә) кимендә 5 ел срок белән арендада җитештерү объектлары булу | юк | 0 |
| | | 300 кв.метрга кадәр | 5 |
| | | 300 кв.метрдан артык | 10 |
| 2. | Җитештерү объектын төзү яисә реконструкцияләү өчен җир кишәрлеге булу | 5 елга һәм аннан да күбрәк срокка аренда | 5 |
| | | милек | 10 |
| 3. | Проект нигезендә булдырырга планлаштырылган эш урыннары саны | 1 эш урыны | 0 |
| | | 2 эш урыны | 5 |
| | | 3 һәм аннан да күбрәк эш урыннары | 10 |
| 4. | Проектның файда китерә башлау срогы (проектта китерелгән исәп-хисапның дөреслеге) | 3 елдан артык | 0 |
| | | 2 елдан 3 елга кадәр | 5 |
| | | 2 елга кадәр | 10 |
| 5. | Чыгымнар планыннан матди-техник базаны үстерү өчен үз акча суммасы | 11 – 20% | 5 |
| | | 20%тан артык | 10 |
| 6. | Яңа эшли башлаган кооперативта авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре булган әгъзалар саны | 11 – 15 әгъза | 5 |
| | | 15 әгъзадан артык | 10 |
| 7. | Яңа эш башлаучы кооперативлар белән конкурс комиссиясе уздырган турыдан-туры әңгәмә нәтиҗәләре буенча проектны бәяләү (7.1 – 7.3 пунктлар буенча күрсәткечләр суммасы) | | |
| 7.1. | Проектны гамәлгә ашыру өлкәсендә яңа эшли | югары | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | башлаган кооператив рәисе компетенциясе дәрәҗәсе, технология һәм чыгарыла торган продукцияне җитештерүне (эшкәртүне) оештыру өлкәсендә җитәрлек компетенцияләр булу, агымдагы базар вәзгыятендә ориентлашу сәләте һәм финанс һәм идарә өлкәсендә күнекмәләр булу | уртача | 2 |
| | | түбән | 1 |
| | | бик түбән* | 0 |
| 7.2. | Проектта билгеләнгән аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрнең дөреслеге һәм чынбарлык туры килү дәрәҗәсе (исәпләүләр проектында тәкъдим ителгән төгәллек, чынбарлык; проект аның нәтиҗәлелек һәм чынбарлык критерийларына туры килүе) | югары | 3 |
| | | уртача | 2 |
| | | түбән | 1 |
| | | бик түбән* | 0 |
| 7.3. | Проектны гамәлгә ашырганда рисклар дәрәҗәсе | түбән | 3 |
| | | уртача | 2 |
| | | югары | 1 |
| | | бик югары* | 0 |

*7.1, 7.2 пунктлар буенча «бик түбән» билгесе конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан, әгәр яңа эш башлаган кооперативның проектны гамәлгә ашыру өлкәсендә компетенциясе булмаса, проектта белдерелгән нәтиҗәләр дөрес һәм чынбарлыкка туры килмәсә, куела; 7.3 пункты буенча «бик югары» билгесе проектта белдерелгән нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирми торган риск дәрәҗәсе булганда куела.»;

5.6 пунктның беренче абзацында «80» саннарын «69» саннарына алмаштырырга, «25» саннарын «15» саннарына алмаштырырга;

7.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Яңа эш башлаган кооператив рәисе, грант алу датасыннан 24 айдан да соңга калмыйча, Министрлыкка Министрлык боерыгы белән расланган «Җыелма реестр» формасы буенча Идарә башлыгы тарафыннан расланган грантны максатчан куллану турында йомгаклау хисабын, яңа эш башлаган кооператив тарафыннан акчаны үз вакытында һәм максатчан файдалануны раслый торган хисап-финанс документларын (грант акчасының хәрәкәтен раслый торган исәп-хисап счетыннан банк өземтәсе, сатып алу-сату шартнамәләре, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счет-фактуралар, фотосурәтләр, башкарылган эшләрнең проект документациясенә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән туры килүенә килештерелгән КС-2 номерлы статистика формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар, КС-3 номерлы статистика формасы буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар бәясе турында белешмә кәгазьләре, төзегәндә (реконструкцияләгәндә) җитештерү объектын эксплуатациягә тапшыруга рөхсәт, төзегәндә (реконструкцияләгәндә) җитештерү күчемсез мөлкәт объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.»;

түбәндәге эчтәлекле 7.5 пункт өстәргә:

«7.5. Әлеге Тәртипнең 1.5 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән юнәлеш буенча грант бирелгәндә, грант алучы, килешү төзелгән көннән алып 6 айдан да соңга калмыйча, Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе һәм (яки) капиталь төзелеш объектын төзүнең яки реконструкцияләүнең, яки капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәсе (катлар саны ике каттан артмаган аерым торган капиталь төзелеш объектлары өчен (аларның гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил итә));

проект-смета документациясе;

төзелешкә рөхсәтнамә күчермәсе (грантны төзелешкә яисә реконструкцияләүгә кулланылганда);

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәсе күчермәсе;

үз-үзен җайга сала торган оешмага керергә рөхсәте булган оешма белән җитештерү объектларын төзегәндә, яисә реконструкцияләгәндә, яисә капиталь ремонтлаганда эшләрнең сыйфатына һәм күләменә төзелеш контролен гамәлгә ашыру карала торган шартнамә күчермәсе.

Чыгымнар планында күрсәтелгән смета бәясенә карата дәүләт экспертизасы узган капиталь төзелеш объектын төзүнең, яисә реконструкцияләүнең, яисә капиталь ремонтлауның смета бәясеннән арткан очракта, арткан сумма грант алучының үз акчасы исәбеннән финанслана.

Чыгымнар планында күрсәтелгән смета бәясенә карата дәүләт экспертизасы узган капиталь төзелеш объектын төзүнең, яисә реконструкцияләүнең, яисә капиталь ремонтлауның смета бәясеннән түбәнрәк булган очракта, экономияләнгән акча әлеге пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә кире кайтарылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин